# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мәлки авыл җирлегенең Мәлки торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**2023 елның 30 ноябре** **№ 1**

« Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004елның 28 июлендә 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә 2023 елның 20 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта, 2023 елның 22 ноябрендә 11 сәгать 30 минутта, 2023 елның 28 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта, 2023 елның 30 ноябрендә 13 сәгать 30 минутта узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән «Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мәлки авыл җирлегенең Мәлки авылы территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?" соравы буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

а) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:
- территорияне торак пунктның рөхсәтсез чүплекләреннән чистарту;
- материаллар сатып алып, Урюм елгасы аша плотинаны ныгыту буенча чара ;
б) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:
- материаллар сатып алып, сууткәргеч челтәрләрен ремонтлау;
в) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
- торак пунктлар чикләрендә автомобиль юлларын тоту;
г) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;
- материаллар сатып алып зиратны чистарту, төзекләндерү һәм ремонтлау ".

Экономия барлыкка килгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлеге башкарма комитетына җыен белән билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

« РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 280 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 155, бу 55 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"Риза" позициясе өчен гражданнар җыенында 155 катнашучы тавыш бирде; "Каршы" позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлегенең Мәлки торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. «Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мәлки авыл җирлеге Мәлки авылы территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?

- а) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:
- территорияне торак пунктның рөхсәтсез чүплекләреннән чистарту;
- материаллар сатып алып, Урюм елгасы аша плотинаны ныгыту буенча чара ;

б) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:
- материаллар сатып алып, суүткәргеч челтәрләрен ремонтлау;

в) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
- торак пунктлар чикләрендә автомобиль юлларын тоту;

г) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;
- материаллар сатып алып зиратны чистарту, төзекләндерү һәм ремонтлау;
- Мәлки авылы зиратларын чистарту, материаллар сатып алу һәм ремонтлау.» - соравы буенча карар кабул ителгән дип санарга.

Экономия барлыкка килгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлеге башкарма комитетына җыен белән билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мәлки авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мәлки авыл җирлеге Башлыгы — Ф.П.Поляков